# «Якты юл» да үтте бәхетле елларым»



Сугыш чоры, сугыштан соңгы елларның бөтен ачысын сабый чагыннан ук татырга туры килгән аңа. Тик авырлыктан иңнәре сыгылган, үксезлектән үзәкләре өзелгән мизгелләрдә дә яктыга, яхшыга омтылган. «Бүген миннән дә бәхетле кеше юк», – ди әңгәмәдәшем – 53 ел гомерен Тукай районының «Якты юл» газетасы белән бәйләгән талантлы зат, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре Заһидә Мотыйгулла кызы Нәбиуллина.

*– Күркәм юбилеегыз белән котлыйм, Заһидә апа! Кайчан гына очрашсак та, йөзегездән елмаю китми, зиһенегез бүген дә яшьләргә биргесез. Сере нәрсәдә?*

– Барысы да балачактан, гаиләдән килә. Тумышым белән Ютазы районы Кәрәкәшле авылыннан мин. 1938 елның 23 июнендә Сәкинә һәм Мотыйгулла Заһидуллиннар гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгәнмен. Икесе дә бик тә талантлы иде. Әти өздереп гармунда уйный, әни аңа кушылып җырлый. Аларга карап мин дә кечкенәдән иҗатка талпындым. Урал тавы итәгенә сыенып утырган авылыбызның табигате дә искиткеч матур һәм бай иде. Сугыш елларында шуннан туендык, урманнан кайтып кермәдек. Озын гомер юлына җитәрлек егәрлекне дә, тормышка булган мәхәббәтне дә мәңге җуелмаслык итеп күңелләргә иңдердек. Шуңа күрә тормыш авырлыклары да сындырмады. Ә язмыш безнең гаиләгә шулкадәр миһербансыз булды! Ахыр чиктә сөекле әтиебезнең хыянәте белән кыйнады...

*– Ничек шулай килеп чыкты соң? Бу хакта бер тапкыр да сөйләгәнегез булмады...*

–Чөнки гомер буе сулкылдап торган иң әрнүле ярам ул. Мин беренче сыйныфка кергән елны сугыш бетте, Бөек Җиңү килде. Инәкинең «Тиздән әтиегез кайта, тормышлар җиңеләер, Аллаһы бирсә!», диеп, балкып йөргәне әле дә күз алдымда. Әтине сугышка озатканны да, дүрт ел буе телемнән төшермичә көткәнемне дә, Җиңү көнендә, әтиебез өч машина белән кайта дип, капканы киереп ачып куйганымны да бик яхшы хәтерлим. Тик... дүрт күзләп көтеп алган газиз кешебезгә без кирәк булмадык. Бөтенләй башка кеше булып кайтты ул сугыштан. Алдына утыртып сөйгәнен дә хәтерләмим. Бер еллап кайтып-китеп йөргәннән соң, бөтенләй үк ташлап чыгып китте. Әниебез, мәрхүмә, ничек түзгәндер! Үксенеп елаган чаклар күп булды, «юньле булсагыз, әтиегез ташламас иде!», дип рәнҗетүчеләр дә табылды. Тик без иңнәребезне авырлык баскан саен ныгыдык, чыныктык кына. Кыйнала-сынала үссәк тә, күңел сафлыгын, кешеләргә ышанычны югалтмадык. Бүгенге бәхетем, тормышта, яраткан хезмәтемдә ирешкән уңышларым белән мин, беренче чиратта, газиз инәкиемә бурычлы. Бик тә игелекле, якты күңелле кеше иде мәрхүмә. Ул бит әтигә дә ачу сакламады. «Сугыштан талымсызланып, усалланып кайтты, бичара, барысына да каһәр суккан сугыш гаепле!» дия иде. Җан көче белән тырышып, тырмашып тартты тормыш йөген, бөтен сәламәтлеге бетте, тик рәнҗемәде, усалланмады. Тормышны, кешеләрне шулкадәр яратып яшәде.

*– Бөтен ялгышны да сугышка сылтау дөрес түгел, минемчә. Бигрәк тә газиз балаларыңа карата кылган хыянәтне.*

– Чыннан да, бик авыр үстек. Әти ташлап киткәндә, Әзһәр абыема 12, миңа 7, Фәймәгә 5 яшь, Флүрәбез алты айлык имчәк баласы иде. Инәки колхозда ат урынына эшләде, басудан кайтып кермәде. Олы кыз буларак, ашарга пешердән башлап, бөтен йорт эше, сеңелләрне карау минем өстә булды. Абыем 12 яшеннән колхозда эшли башлады. Кышка утын әзерләшергә дә инәкинең төп таянычы булды. Утын дигәннән, урманнан коры-сары җыярга гына рөхсәт иттеләр. Кышка ягар өчен күбрәк мал астыннан чыккан тирестән "кирпеч" киптердек. Дөрес, башка гаиләдә яшәсә дә, әти ел саен бер машина утын кайтарта иде. Бөтен ярдәме шул булды. Сугыштан каты бәгерьле булып кайтуы да хактыр. Ул чакта гүр иясе булган әнисенең каберенә килгәне дә, кызыксынганы да булмады. Ике ел урын өстендә яткан әбекәйне, инәки тәрбияләп соңгы юлга озатты. Әтине дә һәрчак акларга тырышты. «Атагыз бит ул! Хәлен белеп торыгыз! » дия иде. Үзенең йөзеннән сагыш китмәде. Йон эрләгәндә тәрәзәгә карап:

Тәрәзәнең рамына сабын кыстырдыңмы әллә,
ЕракларДан тавышың килде, сагынып кычкырдың мәллә?

дип җырлаганы әле дә хәтеремдә. Әзһәр абый белән мин барыбер ахыргача гафу итә алмадык әтине. Инәкине кызганып, җаныбыз әрнеде...

Әти ташлап киткән елны терсәктән ямаулы күлмәк белән (әни бик матур итеп ямый иде киемне) яланаяк беренче сыйныфка укырга барганымны мәңге онытмыйм. Пыяла-фәлән юк, барыбыз да яланаяк үстек. Инәки кичтән кер сабыны белән мунчалалап, ышкып юды аягымны. Җәй буе басу эшенә йөреп алҗыган балалар парта артына килеп утырдык. Укытучыбыз Галия апа барыбызны да аркабыздан сөеп чыкты. Иске китап битләре арасына тырышып таяк сызудан башланды гыйлем дөньясына тәүге сәяхәтебез...

*– Беренче тапкыр каләм чарлап каравыгыз, мөгаен, мәктәп елларында башлангандыр?*

– Әйе, 5 сыйныфта укыганда стена газетасына беренче мәкаләмне яздым. Шигырьләр дә сызгалый башладым. Бер дәфтәр тутырып язган шигырьләремне укытучыбыз Рәйсә апа киңәше белән редакциягә дә алып бардым. Инәки районда эшләүче күрше кызына ияртеп җибәрде. Иртәгесен ап-ак йон носки, яңа кәлүш киеп, теге апа белән бергә Ютазыга юл тоттык. Редакция ишеге төбенә килеп җитүгә: «Бар инде, үскәнем, үзең кер», – дип, ул эшенә ашыкты. «Хатлар бүлеге» дигән ишек төбендә кәлүшемне салып куйдым да, эчкә үттем. Елмаеп каршы алдылар ике апа. «Нәрсә йомыш иде, акыллым?», диләр. Кыяр-кыймас кына дәфтәремне суздым. Берсе торып, аркамнан сөйде дә: « Бар, аяк киемеңне киеп кер», – диде. Дәфтәремне алып калдылар, чәйләр эчереп озаттылар. Озак та үтми, «Сыерчыклар кайтты» һәм «Язгы ташу» дигән ике шигырем район газетасында чыкты. Ул көнне күкләргә менеп китәрдәй булып очынып йөрдем. Ике бөртек шигырь, бәлки чынлап шигырь дә булмагандыр, ә баланың беренче талпынышын сүндермәделәр. Миңа шундый канат куйдылар ул апалар, гомерем буе рәхмәт укыйм. Мәктәпне тәмамлаган елны район газетасында «Сау бул, мәктәбем!» дигән күләмле генә язмам басылды. Ул чакта әле мин журналист профессиясе барлыгын да, газетаны махсус әзерлеге булган белгечләр чыгаруын да белми идем.

*– 20 ел бергә эшләү дәверендә Сездән бик күп нәрсәгә өйрәндем, Заһидә апа! Зыялы, тирән гыйлемле, барлык өлкәләрдә дә хәбәрдар булуыгызга гаҗәпләнә идем. Ә бер тапкыр югары белемегез булмавын әйткәч, ышанмадым. Дипломлы белгечләрнең язмаларын төзәтеп утыручы, укып туймаслык очерклар язучы Заһидә апамы югары белемсез?! Ул чакта сәбәбен ачыкларга базмадым.*

– Юклык белән үссәк тә, инәки безнең белемгә, яңалыкка омтылышны һәрвакыт хуплап торды. Шул нияттән, мин алты сыйныфны тәмамлауга, башта күрше Бәрәкә авылына, аннан соң район үзәгенә, Ютазыга күчтек. Гел яхшы билгеләренә генә укыдым. Укытучыларыма гомер буе рәхмәт укыйм. Ә татар теле укытучысы Рәйсә апа туган телнең тәмен белеп укырга өйрәтте. «Китап укыган кешенең теле дә, күңеле дә ярлы була алмый», - дия иде. Габдрахман Әпсәләмов, Аяз Гыйләҗевларның һәр әсәре өстәл китабыма әйләнде. Мөхәммәт Мәһдиевнең «41нче ел балалары» китабын елый- елый ничә тапкыр укып чыктым икән!

Нишлисең, университетларда уку насыйп булмады. Тормышка ашмаган үкенечле хыялым ул минем. Мәктәпне тәмамлауга, инәки авырып китте. Абыем Армиядә, ике кечкенә сеңелемне ашатырга, киендерергә кирәк. Кечкенәбез Флүрәне беренче сыйныфка укырга илттем дә, Чистайга барып, спорт аяк киемнәре тегә торган фабрикага эшкә урнаштым.

*– Тормышыгызның әлеге чоры алдагы җиңүләргә әзерлек мәктәбе булган, күрәсең.*

– Әйе, бөтен Татарстанга танылган фабрикада беренче хезмәт сынавын үттем. Беренче хезмәт хакына үземә кышкы пәлтә, бүрек алып кидем, өскә кияр киемем юк иде бит. Яңадан инәкигә ай саен акча җибәреп тордым. Шушы коллективта 5 ел эшләү дәверендә кешеләр белән матур итеп мөгамәлә корырга өйрәндем, русчам шактый чарланды. Яхшы эшләгәнем өчен Казанга алдынгылар слетына җибәрделәр. Аннары Чистай шәһәр Советына депутат итеп сайладылар. Фоторәсемем мәдәният йортының Мактау тактасында торды. Инәки минем янга килгәч, шаккатты, үзе бик тә горурланды. Фабриканың комсомол секретаре ярдәмчесе дә булдым. Китмә, квартира бирәбез, дигәннәр иде. Тик күңел инде урыныннан кузгалган иде. Сәбәбен еллар узгач кына аңладым. Каләмгә, иҗатка омтылыш шулай алгысыткан мине. Озак та үтми, Әхәт белән таныштык һәм өйләнешеп Чаллыга күчтек.

*– Югары белем алырга кабат бер дә талпынып карамадыгызмы?*

– «Коммунизм байрагы» редакциясендә эшли башлагач, тагын бер тапкыр ымсындырды язмыш. Берничә кешене читтән торып укыту турында сүз чыккач, мин дә теләгемне белдердем. Тик... укырга китәргә йөргәндә, грипп белән бик каты авырдым. Ютәлем һич кенә дә үтмәгәч, беренче редакторым Хәнәфи Гали улы кичекмәстән табибка барырга кушты. Ә анда ныклап тикшерүгә, үпкәдә туберкулез таякчыклары таптылар. Шактый озак вакыт дәваланырга, тернәкләнү курслары үтәргә туры килде. Минем бөтен бәхетсезлегем, сәламәтлегемнең ныклы булмавы, укырга керә алмавым да авырлык белән үсүдә. Әтиебез ташлап чыгып китмәсә, институтларда укымаслык идемме соң?!

Бергә эшләгән хезмәттәшләрем Гамир Гайфетдинов белән Нина Богданова укырга киттеләр, ә мин елап калдым. Алга таба Гамир бөтен контрольныйларын миннән эшләтте. Әдәбият исемлеген, сорауларын алып кайтканын көтеп кенә торам, аннан соң сөенә-сөенә эшлим. Шулай итеп, алар белән бергә журналист мәктәбен тулысынча үттем. Рәсми дипломым гына юк, имтиханын да бирә алыр идем, мөгаен. Әлеге басмада берничә ел тәрҗемәче, әдәби хезмәткәр булып эшләдем. Бик көчле коллектив иде. Баш мөхәррирebез Анатолий Якимович Артемьев та, татар газетасы җитәкчесе Хәнәфи Гали улы Маннапов та Чаллыда журналист мәктәбе оешуның башында тордылар.

*– Димәк, «Якты юл» газетасына шактый тәҗрибә туплап килгәнсез.*

–1976 елның апрелендә Тукай районының «Якты юл» («Светлый путь») газетасы оешты һәм без бөтен тәрҗемә бүлеге белән шунда күчтек. Яратып, чумылып эшли башладым. Яңа коллектив икенче гаиләмә әйләнде, иң бәхетле елларым «Якты юл» да үтте. Баш мөхәррир Дамир Харрас улы Вагыйзов, җаваплы сәркатип Флера Сәет кызы Сәйфетдинова, соңрак килгән җитәкчебез Халидә Бари кызы Гумеровалар белән беренче көннән иңне-иңгә куеп эшләдек. Аннан соң бер-бер артлы сез, талантлы яшьләр, килдегез. Чын иҗат казанында кайнадык. 53 ел эшләү дәверендә тормыш мине күпме яхшы кешеләр, кызыклы язмышлар белән очраштырды! Һәрберсеннән, бал корты чәчәкләрдән бал җыйган кебек, ниндидер яхшылыкка өйрәндем, тәҗрибә тупладым.

Ахыры 7 нче биттә.